…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

**1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.**
**№ 3 2013. Ноябрь**
**«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге**

## *ТЫРЫШКАН ТАБАР, ТАШКА КАДАК КАГАР...*

Мәктәп тормышының иң җаваплы чорына якынлашабыз. Укуның беренче айларыннан ук Бердәм Дәүләт имтиханнарына әзерлек эшчәнлеген башлап җибәрдек. Без, 11 нче сыйныф укучылары өчен төрле вузлардан очрашуга вәкилләр килә. Гомумән, безгә бик җаваплы вакыт, һөнәр сайлау вакыты килеп җитте.

Шул максаттан чыгып мин көзге каникулларда Казанда яшьләр өчен оештырылган телевидение һәм кино сәнгате буенча визуаль иҗат фестивалендә катнашып кайттым. Бу фестивальнең төп бурычы укучылар арасында үзенең киләчәк һөнәрен журналистика һәм телеведение белән бәйләүчеләр өчен әзерлек укулары оештыру иде. Фестивальнең исеме "Алга" . Фестиваль Татарстанда беренче тапкыр оештырылды. Фестивальне оештыручы Павел Сергиеевич Косов. Безне бер атна эчендә журналистика һәм телеведение Һөнәренең нечкәлекләре белән таныштырдылар, дәресләр үткәрделәр. Безне укыткан укутучылар күп булды, ләкин мин шулар арасыннан Дарья Мельникова, Анастасия Александрова, Алмаз Хакимовны аерып әйтәсем килә. Бер атна вакыт эчендә без үзебезгә бик күп кирәкле яңалык тупладык. Безгә монтаж, оператор серләре, актерлык дәресләре үткәрделәр. Шулай ук укыган белемнәребезне практик эштә дә күрсәттек. Безне социаль һәм уен роликлары төшерү серләренә өйрәттеләр. Алдан бүленгән төркемнәр белән без роликлар төшердек һәм безнең төркем төшергән роликның берсе хәтта 3 урынны алды. Һәр роликны жюри тикшерде, бер нәтиҗәгә килү аларга да бик авыр булгандыр, шулай да гадел бәяләп, урыннар билгеләделәр.

Мин бу фестивальгә баруыма бик шат, анда яңа дуслар таптым һәм бик күп белем алдым. Шулай ук мин шушы фестивальне оештыручыларга, миңа шундый мөмкинлек бирүчеләргә, бу фестивальгә баруда булышкан әтиемә, яңа дустым Чирмешән кызы Айгөлгә, аның гаиләсенә рәхмәтем зур.

Ә яшьтәшләремә әйтәсе килгән сүзем шул: мондый мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмаска, һәр чараны үзеңә файдалы итеп уздырырга кирәк икән.




Казанда яшьләр өчен оештырылган телевидение һәм кино сәнгате буенча визуаль иҗат фестивале катнашучы Фәния Вагизова (11 нчы сыйныф укучысы)

## *ЛИДЕР БУЛУ: КЫЕНЛЫКЛАР ҺӘМ МӨМКИНЛЕКЛӘР*



***“ШАГ” агымы: республиканың төрле мәктәпләреннән җыелган дума әгъзалары. 4 нче отряд.Рания Газимзянова 9 нчы сыйныф укучысы.***

*Ноябрь башы безнең өчен аеруча истәлекле булды. Безнең мәктәптән ике укучы – Исәндәр Мөхиббуллин һәм мин – Казанда “Костёр” (“Учак”) Республика балалар сәламәтлек үзәгендә кыска вакытлы укуларда булып кайттык.Ниләр булды һәм ниләр ашаттылар – бусы башка вакытта иркенләп. Өч тәүлеккә ничек шулкадәр күп файдалы информация сыйдыра алганнар, шунысы – гаҗәп. Биредә безне чын лидер нинди сыйфатларга ия булырга тиеш, укучыларның үзидарәсен ничек оештырырга, дума эшчәнлеген нинди юнәлешләрдә алып барырга өйрәттеләр. Шәхес ничек формалаша диган сорауга җавап табу белән бергә, уңышлы формалашу серен дә аңлаттылар. Мәсәлән, лидерлык уңышының 4 серен уртаклашам: беренчесе – “Һәрвакыт яхшыга ышан!” лидер уңышка ышанса, коллектив та аңа иярәчәк; икенчесе – “Төркемең белән горурлан!” һәр төркем олы бер дөнья, аны теләкләрен исәпкә ал, аларга таян; өченчесе – “Барысын да күрергә кирәк!” төркемдә “күренми торган кешеләр” булмасын; дүртенче – “тыела бел!” хисләреңне контрольдә тот, вакытында тыела бел, чама хисен югалтма!. Менә шулар.*

## КИТАП – БЕЛЕМ ЧИШМӘСЕ. ШУЛАЙ ИДЕ, ШУЛАЙ БУЛАЧАК ТА!!!

Республика күләмендә “Подари книге вторую жизнь” шәфкатьлелек акциясе үткәрелде. 2013 нче елның 30 нчы маенда старт алган әлеге акциянең төп максаты - китапханәләрнең фондын фәнни-популяр әдәбият, дәреслекләр, телара һәм аңлатмалы сүзлекләр белән баету иде. Шулай ук яшь буында укуга кызыксыну уяту, китапка сакчыл караш, гуманизм һәм шәфкатьлелек тәрбияләү максатларын да алга куйды бу акция. Бу күркәм эшкә ата-аналар, укытучылар, мәктәп хезмәткәрләре, укучылар үз өлешләрен кертә алалар. Безнең мәктәп коллективы бу акциядә ничек катнашты соң? Иң актив катнашучы - педагог-оештыручы Динмөхәммәтова Галия Минзагит кызы – ул китапханә фондына 56 китап (төрле юнәлештәге белешмә әдәбият, детектив әсәрләр) тапшырды. Укучылар арасыннан 5 нче сыйныф укучысы Архипова Раилә бик кызыклы 12 әдәби китап – чит ил язучылары әсәрләрен тапшырды. Коллективның күп өлеше әлеге акциягә битараф калмады: Гайсина Гүзәлия Идрис кызы, Газимзянова Ралия Габбас кызы, Нуруллина Кадрия Шәхит кызы, Шакирзянова Рәзидә Ахмадулла кызы, Галимова Резеда Минзакир кызы, Абунагимова Галия Сәлихҗан кызы китаплар алып килделәр. Шулай да Сафина Мәдинә Шәфикъ кызы, Динмөхәммәтова Кадрия Рәфгать кызы, Дәүләтшина Халидә Галимҗан кызы бу эшкә аеруча җаваплы карадылар. 4 нче сыйныф укучысы Гатауллин Алмаз, 10 нчы сыйныф укучылары Мөхәммәтҗанова Раилә, Зиатдинова Налияләрне аерып күрсәтәсе килә. Уртак тырышлык белән барлыгы 210 китап җыелды, димәк мәктәп китапханәсенең фонды бераз баеды, тулыланды.

Белдерү ясалып, аңлату эшләре алып барылса да, укучылар арасында битараф калучылар да булды. Алай гына түгел, кайбер укучылар китапханәдән алган китапларның номерларын, битләрен буяп, үзләренеке дип китерәләр. Бары тик өендә булган, үзең сатып алган яки бүләк ителгән китапларны гына китерә аласың. Әле акция дәвам итә, үз өлешегезне кертергә – мәктәпкә, китап сөючеләргә истәлек калдырырга өлгерәсез. Китерелгән китаплар укучылар кулында булырга да өлгерде инде. 10 нчы сыйныф укучысы Бадаев Фирдүс детектив әсәр, ә югары сыйныф укучылары Нәбирә Гыйматдинованың “Бер тамчы ярату” китабын кулдан-кулга йөртеп укыдылар.

Бу акциядә катнашып, мәктәп китапханәсен баетуга өлеш керткән бу китап сөючеләргә зур рәхмәт белдерәбез, акциянең йомгаклау өлешендә призлар, мактау кәгазьләре булыр дип калабыз.

***Мәктәп китапханә советы.***

# Шигъри почмак

Бу серле елмаеп торучы кыз - 7 нче сыйныф укучысы Срургдинова Ләйлә. Аның бик матур биегәнен, рәсем ясаганын инде күпләр белә торгандыр. Өлгер кешедән барысы да була, ул әле күңеленә илһам килгәндә шигырьләр дә яза икән. Шуның өстенә ул әле әнисенең уң кулы, ике сеңелесенә кайгыртучан апа да. Афәрин, Ләйлә!. Сәләт чишмән саекмасын, синнән тагы шигырьләр көтеп калабыз.



**“Әнкәй”**

**Ул бит безгә һәр көн назын бирә,**
**Ул бит безне карап үстергән.**
**Туган көнебездән “алмам” диеп,**
**“Алтын җимешем” дип үстергән.**
**Нурлы якты йөзе белән безгә карап,**
**Бәхет-шатлык кына тели ул.**
**“Балам “ диеп безне назлап тора,**
**Җылы йомшак кулы белән ул.**

***“Сау бул, көз!”***

***Яңгырлары белән елый-елый***
***Саубуллашыр инде тиздән көз.***
***Сары яфраклары белән куыш уйнап***
***Шыпырт кына качар инде көз.***
***Сары сагышларны алып китеп,***
***Ап-ак матур кышны чакырыр.***
***Ә тагын түгәл бер ел үткәч***
***Алтын табигатен кайтарыр.***

*Кышкы кич*
*(этюд)*

*Яратам мин кышның кичен.*
*Яратам саф һавасын.*
*Һич онтылмый матур кышның*
*Тылсымлы матур чагы.*

*Ай яктысы җиргә төшеп*
*Ялтырата карларны*
*Бу карлар хәтерләтә*
*Матур асылташларны.*

*Тыныч бу кич, матур бу кич.*
*Бураны да юк аның.*
*Шушы матурлыкка карап*
*Моңланып утырамын.*

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**

# Сәламәт тәндә –

## САК БУЛЫГЫЗ: ТӨЗ АТАБЫЗ!



Татлы да соң ЖИҢҮ мизгелләре!!!



Ну, “унлык” держись!!!

Көзге каникулның ахыры безнең өчен бик истәлекле булды. Без – Лашман урта мәктәбенең жәядән ату буенчы жыелма командасы – Балык Бистәсенә спартакиадага бардык. Безне биредә бик яхшы каршы алдылар. Барган көнне үк безнең әзерлекне Россия күләмендә танылган остазлар карап, унай яктан бәяләделәр, ялгышларыбызны әйтеп, киңәшләр әйттеләр.

Ярышта катнашучыларның географиясе бик киң иде – республикабызның төрле район һәм шәһәрләреннән әлеге спорт төре белән кызыксынучылар биредә жыелган иде. Икенче көнне ярышлар башланды. Иң көчлеләр арасында без дә сынатмадык. Безнең командадан Зөфәрова Ләйлә икенче урынны алды.

Үзенчәлекле һәм бик кызыклы спорт төре белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр тудырган Фаиз абый Биляловка бик зур рәхмәтебезне житкерәсебез килә. Алда тагы ярышлар һәм жиңүләр көтсен безне!!!

*Мөхиббуллин Искәндәр. 8 нче сыйныф укучысы*



Ну, егетләр, белегез! Безнең белән шаярырга ярамый!




Шундый оста булуыма үзем дә шаккатам!

## РӘХӘТ ТӘ СОҢ ШУГАЛАКТА!!!



Менә без нинди активлар!



Сәетне шуарга өйрәткәндә...

Без, 9 нчы Б сыйныфы, 13 ноябрь көнне боз сараена төштек. Боз сараена инде 5 сыйныфтан бирле жыенабыз, тик төшеп житеп кенә булмый шул. Уйлап карасаң: Чирмешән-Лашман арасы алай ерак та түгел инде. Әле автобус булмый. Әле автобус булып, бензины булмый. Автобусы бензинлы булса да, боз сарае эшләми икәнлеге билгеле була. Ә бит ниһаять төштек, туйганчы шуыдык.Безгә бик кызык булды һәм бик ошады. Әйдәгез тагын киләбез диешкән булдык. Тик шулай да барысы да үзебездән тора, калганы Илһам абый кебек укытучыга бәйле инде. Мин шулай ук сезгә кечкенә фоторепортаж тәкъдим итәм. ( Әгәрдә боз сарена бару теләгегез бар икән, бирешмәгез, ахыргача көрәшегез. Иң мөһиме теләк, калганы була аның. )



И-и-ии, кайчан үсәрсең инде!



“Автомато, автомато, дай нам шоколата...”

# Сәламәт рух

## КӨРӘШ ДИЮЛӘРЕ ГЕНӘ ҖИҢЕЛ...



Хөкемдарларга да җиңел булмагандыр.



Болар безнең ЕГЕТЛӘР!!!

Көзге каникул көннәрендә район үзгендә алтмышлап спортчы – мәктәп укучысы милли көрәштә көч сынашты. Район мәгариф бүлеге оештырган әлеге бәйгедә безнекеләрүз өстенлекләрен еш дәлилләде - мәктәпнең көрәш командасы 1 нче урынны яулады! Күтәмә, Ивашкино, Бәркәтә, Лашман, Ульяновка, Чирмешән авылларыннан – авырлыклары 30 килограммга кадәрле кечкенә малайлардан алып, 70 килограммны узган егетләр келәмдә бил алышты..Көрәш – ансат эш түгел. Атнасына өчәр тапкыр күнегүләргә йөрү өчен вакыт та, ихтыяр көче дә кирәк.Үзеңне һәрвакыт формада тоту да бик җиңеллрдән түгел.

Бәйге нәтиҗәләренә килгәндә, бөтен өстенлек безнекеләр ягында иде. Тренер Рафик Гатин шәкертләре Руслан Вафин, Нәзир Ибәтуллин, Айнур Вафин, Рузил Талипов, Данияр Гайфетдинов, Рифат Талипов, Зөлфәт Зиннуров үз үлчәүләрендә җиңүче булдылар. Мондый егетләр булганда, курыкмый яшәргә була!!!



Көтә-көтә арыдык та...



Чыдасын гына билләр!!!

## БЕЗНЕҢ ЙОЛДЫЗЛЫ СӘГАТЬ...

**16 нчы ноябрьдә безнең мәктәпнең йөзүчеләр командасы (тренеры Фаиз абый Билялов) Яңа Чишмәдә районара бәйгедә катнашты. Биредә Норлат, Чистай, Яңа Чишмә һәм Чирмешән-Лашман йөзүчеләре көч сынашты. Бәйгене безнең команда өчен чын мәгънәсендә йолдызлы сәгать булды дисәк тә була. Медальләр агылып кына торды. Беренчелекнең кубогы да бездә булды. Тырышлыкның нәтиҗәсе бар шул. 8 дистанциядә 1 нче урынны алырлык ( икенче һәм өченче урыннарны мин санамадым әле) команданы әзерләү Фаиз абыйдан күп сабырлык һәм көч таләп иткәндер. Беренчелекне бәяләп бирелгән кубокны кулга алганда мин никтер шул хакта уйладым... Ә җиңүнең татлы хисе күңелләрдә әле озак сакланыр.**

**Рания Газимзянова 9 нчы сыйныф укучысы**



Кубок – БЕЗДӘ!!!